МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

25.12.2014 Казан ш. № 3004-р

**Татарстан Республикасының Югары Ослан, Кама Тамагы (өлешчә), Яшел Үзән (өлешчә) муниципаль районнары территорияләрендәге газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналары чикләрен расларга:

1.1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан 329,398 км озынлыктагы, территориясе 1,362903 кв.км (1 362 903 кв.м) гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Граница» кадастр үзәге”

ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 12 декабренә кадәр башкарылган һәм 2013 елның 22 декабендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналары картасына (планында) булган мәгълүматлар буенча.

1.2. Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә урнашкан (өлешчә) 2,54 км озынлыктагы, территориясе 10 498 кв.м гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Граница» кадастр үзәге” ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 12 декабренә кадәр башкарылган һәм 2013 елның 22 декабендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналары картасына (планында) булган мәгълүматлар буенча.

1.3. Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә урнашкан (өлешчә) 811 м озынлыктагы, территориясе 3 246 кв.м гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Граница» кадастр үзәге” ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 12 декабренә кадәр башкарылган һәм 2013 елның 22 декабендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналары картасына (планында) булган мәгълүматлар буенча.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖенә тәкъдим итергә:

1) газүткәргечнең саклау зоналары турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә кергән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән

мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне күчемсез милек дәүләт кадастрына кертү өчен «ФКП Росреестр»ның Татарстан Республикасы буенча филиалына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Э.Г. Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**